ГЛАВА
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.10.2023 с. Введенская Слобода №5

«Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Елизаветино авылында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 14 октябренә Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Елизаветино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Елизаветино авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллау белән килешәсезме:
- Елизаветино авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау
«ӘЙЕ» «ЮК»
3. Гражданнар җыенын Елизаветино авылы, Солнечная ур., 19 йорт адресы буенча йорт яны территориясендә 12:00 сәгатьтә уздырырга.
4. Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов